**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы турында» Указына һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында чараларны планлаштыру һәм контроль системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2011 елның 27 маендагы ПУ-295 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 2 ноябрендәге ПУ-913 номерлы, 2014 елның 18 апрелендәге ПУ-376 номерлы, 2016 елның 11 мартындагы ПУ-235 номерлы һәм 2021 елның 23 августындагы ПУ-655 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 3 пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе» сүзләренә алмаштырырга;

б) «Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы турында нигезләмәдә:

4 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының Эксперт департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Эксперт департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

20 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

21 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының Эксперт департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Эксперт департаменты» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында чараларны планлаштыру һәм контроль системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2015 елның

19 ноябрендәге ПУ-1112 номерлы Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 3 пунктта:

икенче абзацта «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

в) «Татарстан Республикасында чараларны планлаштыру һәм контроль системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турында нигезләмәнең 4 пунктындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисенең;».

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел, 15 апрель
№ 235